# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Зәй районы һәм Зәй шәһәре буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Зәй районы һәм Зәй шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 130-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
Зәй районы һәм Зәй шәһәре буенча
Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Татарстан Республикасы Зәй районы һәм Зәй шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

### 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Нариманов урамында Кармалка елгасы аша сузылган автомобиль юлы күпере уртасында урнашкан ноктадан алып елга үзәне буйлап, сул ярда (Түбән урамы буйлап) урнашкан йортларны кертеп, аның агымына каршы көньяк-көнбатышка таба Заречная урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан автоягулык салу станциясен кертеп, Заречная урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Баныкин, Октябрь, Ленин урамнары һәм Җиңү проспекты кисешкән ноктага кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Октябрь урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Газовая урамы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба әлеге ноктадан алып, «Воздвиженка» 7 нче микрорайонын кертеп, Октябрь урамының дәвамы булып туры сызык буйлап көньякка таба шәһәрнең көньяк чигенә кадәр бара, аннары «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнбатышка таба шәһәрнең көнбатыш чиге Бугульдинка елгасы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба борыла һәм елга үзәне буйлап, аның уң ярын кертеп, Юбилейная урамында урнашкан күпергә кадәр бара, аннары Юбилейная урамы күчәре буйлап көньякка таба тимер юл тармагына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба борыла һәм, уң якта урнашкан территорияне кертеп, тимер юл тармагына бүлеп бирелгән полоса буйлап Пушкин һәм Завод урамнары белән кисешү ноктасына кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Завод урамы күчәре буйлап көньякка таба, Автодорожная һәм Нариманов урамнары белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба Нариманов урамы буйлап бара, уң якта урнашкан йортларны (Завод урамындагы 10 һәм 11 нче йортлар, Тавлин урамындагы йортлар) кертеп, оешманы (Нариманов урамы, 16) урап уза, аннары, уң якта урнашкан территорияне («Салават күпере» бакчачылык ширкәте) кертеп, Нариманов урамы буйлап Кармалка елгасы аша сузылган автомобиль юлы күперенең уртасында урнашкан ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе, Баграж,

Бигеш, Югары Налим, Югары Пәнәче, Югары Шепкә, Дүртмунча, Кадер, Түбән Биш һәм Поповка авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көньяк чиге Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба уза, аннары, уң якта урнашкан территорияне кертеп, Нариманов урамы күчәре буйлап М.Никифоров урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба М.Никифоров урамы буйлап көнбатышка таба автомобиль кую урынына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, уң якта урнашкан йортларны кертеп, М.Никифоров урамындагы 85 нче йорт һәм Ленин урамындагы 27, 29 һәм 31 нче йортлар яныннан Ленин һәм Надежда урамнарының кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап төньякка таба Крупская урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көнчыгышка таба борыла һәм, Комсомол урамында урнашкан йортларны кертеп, Крупская һәм Комсомол урамнарында урнашкан йортлар арасыннан Энергетиклар урамына кадәр уза, алга таба, Энергетиклар урамында урнашкан йортларны кертеп, Крупская һәм Энергетиклар урамнарында урнашкан йортлар арасыннан төньякка таба Лобачевский урамына кадәр бара, аннары көнбатышка таба борыла һәм, Энергетиклар һәм Нефтяниклар урамнарында урнашкан йортларны кертеп, Лобачевский, Энергетиклар һәм Нефтяниклар урамнарында урнашкан йортлар арасыннан Ленин урамына кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап төньякка таба Баныкин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Баныкин урамы күчәре буйлап Нариманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Нариманов урамы буйлап Промышленная урамына кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Промышленная урамы күчәре буйлап көнчыгышка таба Бөгелмә – Чаллы тимер юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, аннары төньякка таба борыла һәм, уң якта урнашкан территорияне кертеп, тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап шәһәрнең төньяк чигенә кадәр уза, алга таба «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнчыгышка таба шәһәрнең көньяк чиге Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Зәй муниципаль районының Бохарай, Яңа Спас, Сармашбаш, Яктыкүл һәм Урсай авыл җирлекләре.

**3 нче суд участогы**

3 нче суд участогы чигенә «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көньяк чиге Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып

автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба Нариманов урамына кадәр уза, аннары, сул якта урнашкан территорияләрне кертеп, аның күчәре буйлап М.Никифоров урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба М.Никифоров урамы буйлап көнбатышка таба автомобиль кую урынына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, сул якта урнашкан территорияне кертеп, М.Никифоров урамындагы 85 нче һәм Ленин урамындагы 27, 29 һәм 31 нче йортлар яныннан Ленин һәм Надежда урамнары кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап төньякка таба Крупская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көнчыгышка таба борыла һәм, Крупская урамындагы йортларны кертеп, Крупская һәм Комсомол урамнарында урнашкан йортлар арасыннан Энергетиклар урамына кадәр бара, алга таба, Крупская урамындагы йортларны кертеп, Крупская һәм Энергетиклар урамнарында урнашкан йортлар арасыннан төньякка таба Лобачевский урамына кадәр уза, аннары көнбатышка таба борыла һәм, Лобачевский урамындагы йортларны кертеп, Лобачевский, Энергетиклар һәм Нефтьчеләр урамнарында урнашкан йортлар арасыннан Ленин урамына кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап төньякка таба Баныкин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, сул якта урнашкан оешмаларны кертеп, Баныкин урамы күчәре буйлап Нариманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Нариманов урамы буйлап Промышленная урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, сул якта (Свердлов, Чехов, Луговая урамнарында) урнашкан йортларны кертеп, Промышленная урамы күчәре буйлап көнчыгышка таба Бөгелмә – Чаллы тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешү ноктасына кадәр бара, аннары төньякка таба борыла һәм, сул якта урнашкан йортларны һәм оешмаларны кертеп, тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап шәһәрнең төньяк чигенә кадәр уза, алга таба «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнбатышка таба шәһәрнең көнбатыш чиге Бугульдинка елгасы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба көнчыгышка таба борыла һәм, сул ярны кертеп, елга үзәне буйлап Юбилейная урамында урнашкан күпергә кадәр уза, аннары Юбилейная урамы күчәре буйлап көньякка таба тимер юл тармагына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, алга таба көнчыгышка таба борыла һәм, 11 нче микрорайонны кертеп, тимер юл тармагына бүлеп бирелгән полоса буйлап Пушкин һәм Завод урамнары белән кисешү ноктасына кадәр уза, аннары, сул якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Завод урамы күчәре буйлап көньякка таба Автодорожная һәм Нариманов урамнары белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба Нариманов урамы буйлап, әлеге урамда урнашкан йортларны кертеп, Кармалка елгасы аша сузылган автомобиль юлы күперенең уртасында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары, уң ярны кертеп, елга үзәне буйлап аның агымына каршы көньяк-көнбатышка таба Заречная урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, «Турист» гараж җәмгыятен кертеп, Заречная урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Баныкин, Октябрь, Ленин урамнары һәм Җиңү проспекты кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Октябрь урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Газовая урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба әлеге ноктадан алып, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Октябрь урамының дәвамы булып

туры сызык буйлап көньякка таба шәһәрнең көньяк чигенә кадәр уза, аннары «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнчыгышка таба шәһәрнең көньяк чиге Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

3 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Зәй муниципаль районының Аксар, Гулкин, Поручик, Сәвәләй, Иске Маврино, Төги һәм Чыбыклы авыл җирлекләре.